ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТУРИЗМУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТУРИСТЛЫК БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

18.07.2022 Казан ш. № 110

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының «Социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2019 елның 16 маендагы 50 номерлы боерыгы белән расланган Социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт башкарма хакимият органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр турында» 2022 елның 28 февралендәге 175 номерлы карары нигезендә б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының «Социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында

бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2019 елның 16 маендагы 50 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының 2019 елның 23 декабрендәге 227 номерлы, 2020 елның 27 июлендәге 82 номерлы, 2021 елның 19 апрелендәге 64 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертеп, аны яңа редакциядә (кушымтада бирелә) бәян итәргә.

2. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары Г.М.Сафинга йөкләргә.

Рәис С.Е. Иванов

Татарстан Республикасы
Туристлык буенча дәүләт
комитетының 2019 елның 16
маендагы 50 номерлы
боерыгы белән расланды
(Татарстан Республикасы
Туристлык буенча дәүләт
комитетының 18.07.2022
№ 110 боерыгы
редакциясендә)

# Социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – Регламент) социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – дәүләт хезмәте) тәртибен һәм стандартын билгели.

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр: «Коммерциясез оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясындагы $2^2$ пунктының 1 пунктчасында каралган социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар (алга таба – социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар, коммерциясез оешмалар).

1.3. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә (мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү варианты нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган үткәрә торган анкета нәтиҗәсендә билгеләнгән мөрәҗәгать итүченең тиешле билгеләренә туры килә торган дәүләт хезмәте күрсәтү) профильне яңасына үзгәртү үткәрелми.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәте атамасы.

Социаль юнәлешле коммерциясез булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр (алга таба – бәяләмә) бирү.

2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның исеме.

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитеты.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар һәм гаризаны кабул итүдән баш тарту турында карар дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәк (алга таба – КФҮ) белгече тарафыннан кабул ителми.

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 26 гыйнварындагы 89 номерлы карары белән расланган кагыйдәләргә 2 нче кушымта нигезендәге форма буенча социаль юнәлешле коммерциясез оешма тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмә яки әлеге Регламентның 2 нче кушымтасына туры китерелгән формада бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерү.

Мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе түбәндәгечә алынырга мөмкин:

язмача формада мөрәҗәгать итүчегә шәхсән;

электрон документ яки электрон документның кәгазь күчермәсе формасында;

Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты (алга таба – Дәүләт комитеты) тарафыннан кәгазь чыганакта чыгартылган рәвештә җибәрелгән, КФҮ мөһере һәм КФҮ хезмәткәре имзасы белән таныкланган электрон документ нөсхәсе формасында КФҮ аша;

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында (http://uslugi.tatarstan.ru) (алга таба – Татарстан Республикасы порталы);

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru) (алга таба – Бердәм портал);

Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документ мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне бирелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документны гаризада күрсәтелгән элемтә ысулыннан файдаланып (почта, электрон адрес, факс буенча, Бердәм порталдагы шәхси кабинет, Татарстан Республикасы порталындагы шәхси кабинет аша) җибәрү Дәүләт комитеты рәисе бәяләмәне (бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезләнгән белдерүне) имзалаган көннән башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү срогы.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан почта аша җибәреп яисә шәхсән тапшырылган булса, дәүләт хезмәте Дәүләт комитеты тарафыннан гаризаны һәм документларны Дәүләт комитетында теркәгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган 14 көнлек чорда күрсәтелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза һәм документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан КФҮ аша тапшырылган очракта, дәүләт хезмәте гариза һәм документлар Дәүләт комитетында теркәлгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган 14 көнлек чорда, шулай ук КФҮ регламентында каралган чорны исәпкә алып күрсәтелә.

Бердәм портал яисә Татарстан Республикасы порталы аша дәүләт хезмәте электрон рәвештә гариза һәм документлар Дәүләт комитетында теркәлгәннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган 14 көн эчендә күрсәтелә.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 26 гыйнварындагы 89 номерлы карары белән расланган кагыйдәләрнең 6 пункты нигезендә Дәүләт комитеты

тарафыннан рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрелгән очракта, әлеге вакыт 30 календарь көнгә озайтылырга мөмкин.

Әлеге карарны кабул итү вакытын арттыру турында Дәүләт комитеты мөрәҗәгать итүчегә бәяләмә бирү турында оешмадан гариза алынган көннән башлап 5 эш көне эчендә хәбәр итә.

Россия Федерациясе законнарында дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.

2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен хокукый нигезләр.

Бердәм порталда, Татарстан Республикасы порталында һәм Дәүләт комитетының рәсми сайтында урнаштырылган:

дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) турында белешмәләр;

дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт яки муниципаль хезмәткәрләрнең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат

2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге.

Документлар:

Регламентка 1 нче кушымтага туры китерелгән форма буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза);

мөрәҗәгать итүченең (мөрәҗәгать итүче вәкиленең) шәхесен таныклаучы документ күчермәсе;

оештыру документларының күчермәләре;

мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен таныклый торган, мөрәҗәгать итүче исеменнән эш йөртү өчен кирәкле ышаныч кәгазе, – документлар мөрәҗәгать итүченең вәкиле аша тапшырылган очракта.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан оешма күрсәтә торган хезмәтнең иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтү сыйфатын бәяләү критерийларына туры килүен нигезли торган документлар (белешмәләр, сыйфатламалар, эксперт бәяләмәләре, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары каршындагы иҗтимагый советларның бәяләмәләре һәм башкалар) теркәлергә мөмкин.

Әгәр мөрәҗәгать итүче тиешле иҗтимагый файдалы хезмәт төре буенча социаль хезмәтләр белән тәэмин итүче затлар реестрына кертелгән булса, мөрәҗәгать итүче тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәяләү буенча билгеләнгән критерийларга туры килүен нигезли торган өстәмә документларны тапшыру таләп ителми.

2.6.1. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында түбәндәгеләр алына:

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 44-ФЗ номерлы федераль закон) нигезендә төзелгән контрактларны үтәү кысаларында гариза бирелгән елга кадәр ике ел дәвамында социаль юнәлешле коммерциясез оешманың хезмәт күрсәтү

нәтиҗәләре буенча намуссыз тәэминатчылар (подрядчылар, башкаручылар) реестрында булмавы турында белешмәләр (Татарстан Республикасы буенча Монополиягә каршы федераль хезмәт идарәсе).

Мөрәҗәгать итүче үз инициативасы буенча әлеге пунктта күрсәтелгән белешмәләрдән торган документларны, шул исәптән, мөмкин булган очракта, электрон рәвештә дә тапшырырга хокуклы.

Югарыда күрсәтелгән белешмәләрдән торучы документларның мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

2.6.2. Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе буенча тапшырыла (җибәрелә) ала:

шәхсән (мөрәҗәгать итүче исеменнән эш итүче зат тарафыннан, ышаныч кәгазе нигезендә) яки кәгазь чыганакларда почта элемтәсе аша. Гариза һәм беркетелә торган документлар, почта элемтәсе аша юлланганда, билгеләнгән тәртиптә раслана;

КФҮ аша кәгазь чыганакларда;

Татарстан Республикасы порталы аша;

Бердәм портал аша.

Гаризаны ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләтле зат тарафыннан рәсмиләштергән очракта, паспорт (шәхесне таныклый торган башка документ), нотариаль таныкланган ышаныч кәгазе яки законнар нигезендә нотариаль таныкланган ышаныч кәгазенә тигезләштерелә торган ышаныч кәгазе күрсәтелә.

Гаризага теркәп тапшырыла торган документларның күчермәләре нотариаль расланырга мөмкин. Нотариаль таныкланган күчермәләр булмаганда, тигез дәрәҗәдә түбәндәгеләр кабул ителергә тиеш:

дәреслеге җитәкченең яки моңа вәкаләт бирелгән вазыйфаи затның имзасы һәм оешманың мөһере (булган очракта) белән таныкланган документларның күчермәләре;

документның төп нөсхәсен күрсәтү шарты белән, таныкланмаган күчермәләр. Шул ук вакытта документның күчермәсе документларны кабул итүче зат тарафыннан төп нөсхәсе белән чагыштырыла.

2.6.3. Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе буенча тапшырыла (җибәрелә) ала:

1) күпфункцияле үзәк аша кәгазьдә һәм Регламентның 2.6.4 пункты таләпләре нигезендә имзаланган (таныкланган) электрон документлар рәвешендә;

2) Бердәм портал, Татарстан Республикасы порталы аша, электрон формада;

3) Дәүләт комитетында шәхсән кабул иткәндә.

2.6.4. Гаризаны һәм кирәкле документларны Бердәм портал, Татарстан Республикасы порталы аша җибәргән очракта, мөрәҗәгать итүчеләр гаризаны гади электрон имза белән имзалыйлар.

Гади электрон имза алу өчен мөрәҗәгать итүчегә электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә файдаланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик бәйләнешләрен тәэмин итә торган инфраструктурада идентификация һәм аутентификация бердәм системасында (алга таба – ИАБС

системасы) теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук стандарттан ким булмаган дәрәҗәгә кадәр исәпкә алу язуын да расларга кирәк.

Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документларны Бердәм портал, Татарстан Республикасы порталы аша тапшырган очракта, мөрәҗәгать итүче мондый документларны төзү һәм имзалау өчен вәкаләтле булган затлар, шул исәптән нотариуслар тарафыннан 63-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон имза белән таныкланган электрон документ образларын яисә электрон формадагы документларны тапшыра.

2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

мөрәҗәгать итүче яисә аның вәкиле тарафыннан Регламентның 2.6 пунктында каралган документларның тулы комплекты тапшырылмаган очракта;

кәгазь чыганакта тапшырылган документларда мәгълүматны һәм белешмәләрне тулы күләмендә файдаланырга, документларның текстын укырга һәм (яки) реквизитларын танырга ирек бирми торган бозулар булган очракта;

интерактив гариза формасында мәҗбүри кырларның дөрес тутырылмавы;

гаризаның (рәсми мөрәҗәгатьнең) һәм электрон формадагы башка документларның законнарны бозып, электрон имзадан файдаланып имзаланган булуы;

электрон документларның аларның форматларына карата таләпләргә туры килмәве һәм (яки) укылмавы.

2.7.1. Гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибендә Бердәм порталда, Татарстан Республикасы порталында, Дәүләт комитетының рәсми сайтында басылып чыккан мәгълүматка туры китереп тапшырылган булса, гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны кабул итүдән баш тарту тыела.

2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре:

күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтнең Россия Федерациясе норматив хокукый актларында аның эчтәлегенә (күләменә, срокларына, күрсәтү сыйфатына) карата билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүдә турыдан-туры катнаша торган затларның (шул исәптән оешмаларның хезмәткәрләренең һәм граждани-хокукый холыклы килешүләр нигезендә җәлеп ителгән хезмәткәрләрнең) кирәкле квалификациясе (шул исәптән югары юридик белеме, юридик өлкәдә эш тәҗрибәсе) булмавы, кирәкле квалификациясе булган затларның исәбе буенча җитешеп бетмәве;

бәяләмә бирелә торган елга кадәрге ике ел эчендә оешманың аның тарафыннан иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтүгә бәйле рәвештәге гамәлләренә (гамәл кылмавына һәм (яки) карарларына карата суд, дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм

муниципаль күзәтчелек органнары, компетенцияләренә туры китереп, башка дәүләт органнары тарафыннан нигезле дип танылган шикаятьләр булуы;

оешма турындагы мәгълүматның ачык һәм аннан файдалана алу дәрәҗәсенең Россия Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләргә (алар булган очракта) туры килмәве;

бәяләмә бирелгән елга кадәрге ике ел эчендә 44-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә төзелгән контрактларны үтәү кысаларында хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча оешма турында намуссыз тәэминатчылар реестрында мәгълүмат булуы;

дөрес булмаган белешмәләре булган документлар яки тиешенчә рәсмиләштерелмәгән документлар тапшырылуы.

Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр юк.

2.8.1. Әгәр дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында Бердәм порталда, Татарстан Республикасы порталында, Дәүләт комитетының рәсми сайтында бастырып чыгарылган мәгълүмат нигезендә тапшырылган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту тыела.

2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары.

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә, кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләрне күрсәтү таләп ителми.

2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатьне тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты.

Мөрәҗәгать итүчене кабул итүне (аңа хезмәт күрсәтелүне) көтү һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алуның максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.

2.11. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгатен теркәүгә алу чоры.

Гариза тапшырылган көнне.

Гариза электрон формада ял (бәйрәм) көнендә килгән очракта – ял (бәйрәм) көненнән соңгы эш көнендә.

Мөрәҗәгать итүче яки аның вәкиле тарафыннан КФҮ аша бирелгән гариза Дәүләт комитеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә гариза КФҮ алынган көнне теркәлә.

2.11.1. КФҮ шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта, гариза тапшырылган көнне мөрәҗәгать итүчегә гаризаның җибәрелгән булуын раслый торган теркәү номеры һәм электрон гаризаны тапшыру датасы белән КФҮ автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан (алга таба – КФҮ АМС) язу бирелә.

2.11.2. Гаризаны Бердәм портал, Татарстан Республикасы порталы аша җибәргән очракта, мөрәҗәгать итүче гариза теркәлгән көнне Бердәм порталдагы, Татарстан Республикасы порталындагы шәхси кабинетында һәм электрон почта буенча гаризаның җибәрелгән булуын раслый торган белдерү ала, анда гаризаның теркәлү номеры һәм тапшырылу датасы күрсәтелә.

2.12. Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр.

Дәүләт хезмәте янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән Дәүләт комитеты биналарында һәм бүлмәләрендә күрсәтелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла.

Инвалидларга, шул исәптән кресло-коляска һәм озата йөри торган этләрдән файдаланучыларга да, биналардан, бүлмәләрдән һәм хезмәт күрсәтүдән файдалана алу шартларын тәэмин итү буенча чаралар гамәлгә ашырыла:

бинага һәм бүлмәләргә каршылыксыз үтеп керү, шулай ук аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән каршылыксыз файдалана алу шартлары;

Дәүләт комитеты территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү, Дәүләт комитеты бинасына һәм бүлмәләренә керү һәм чыгу, транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып;

күрү сәләте һәм мөстәкыйль хәрәкәт функциясе бозылган инвалидларны озатып бару һәм аларга бинада һәм бүлмәләрдә ярдәм күрсәтү;

инвалидларның бинадан, бүлмәләрдән һәм хезмәт күрсәтүләрдән тоткарлыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат җиһазларын тиешенчә урнаштыру;

инвалидлар өчен кирәкле булган, ишетелә һәм күренә торган мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм Брайльның нокталы шрифтлары белән ясалган текстлы һәм тамгалы башка график мәгълүматларны дубльләштерү, сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү;

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртә торган этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм этнең махсус өйрәтелгән булуын раслый торган документы булган очракта, бинага һәм бүлмәләргә сукырларны озата йөри торган этне кертү;

дәүләт хезмәте күрсәтә торган хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган каршылыкларны үтеп чыгарга ярдәм итү.

2.13. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлекле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре.

Дәүләт хезмәтенең һәркемгә күрсәтелә алырлык булуы күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

документларны кабул итү һәм тапшыру эшләре башкарыла торган биналарның җәмәгать транспортыннан файдалана алу зонасында урнашуы;

белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул ителә торган урыннарның да, кирәкле санда булуы;

мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә (алга таба – «Интернет» челтәре), Дәүләт комитетының рәсми сайтында, Бердәм порталда, Татарстан Республикасы порталында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе, сроклары турында тулы мәгълүмат булуы;

дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе, шул исәптән телефон элемтәсе, электрон почта аша, Бердәм портал һәм Татарстан Республикасы порталы, күпфункцияле үзәк аша, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны, шулай ук Дәүләт комитетының рәсми сайтында мәгълүмат алу мөмкинлеге;

күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны аша электрон рәвештә гариза бирү мөмкинлеге;

мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен электрон рәвештә алу мөмкинлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен үтемле булуы;

инвалидларга биналарның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган башка каршылыкларны бетерүдә дәүләт хезмәте күрсәтә торган хезмәткәрләр тарафыннан ярдәм күрсәтү;

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

документларны кабул итү һәм карау чорларының саклануы;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу чорының саклануы;

Дәүләт комитеты белгечләре тарафыннан Регламент бозылуга бәйле прецедентлар (нигезле шикаятьләр) булмавы.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең Дәүләт комитеты белгече белән бер мәртәбә бәйләнешкә керү вакыты 15 минуттан артмый.

Дәүләт хезмәте, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап, аның яшәгән урынына яки фактта яшәгән (торган) урынына бәйсез рәвештә, теләсә кайсы күпфункцияле үзәктә экстерриториаль принцип буенча күрсәтелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Дәүләт комитетында, КФҮ, Бердәм порталда, Татарстан Республикасы порталында алынырга мөмкин.

2.13.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Бердәм порталда яки Татарстан Республикасы порталында шәхси кабинеттан, күпфункцияле үзәктән алынырга мөмкин.

Дәүләт хезмәте күрсәтү, хезмәт күрсәтү тәртибе һәм башка документлар турындагы белешмәләрне карау Бердәм порталда, Татарстан Республикасы порталында «Шәхси кабинет»та мөрәҗәгать итүчене алдан авторизацияләмичә башкарыла.

Бердәм порталда, Татарстан Республикасы порталында «Шәхси кабинет»та авторлашканнан соң мөрәҗәгать итүче түбәндәге мөмкинлеккә ия:

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны бирергә;

кирәк булганда, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның электрон үрнәкләрен (график файлларны) беркетергә;

дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат алырга;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында мәгълүмат алырга.

Гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны электрон рәвештә бирү мөмкинлеген тәэмин итү өчен, мөрәҗәгать итүчедә

гади электрон имза ачкычы булырга тиеш. Гади электрон имзаны алу өчен,

мөрәҗәгать итүчегә ИАБС системасында теркәлү процедурасын узарга кирәк. ИАБС системасында алдан теркәлүнең онлайн-формасы «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтта урнаштырылган («Интернет» челтәрендәге сайтның домен исеме – esia.gosuslugi.ru/).

ИАБС системасында (физик зат буларак) теркәлү процедурасын узганнан соң мөрәҗәгать итүче – физик зат гади электрон имзаны кулланып, Бердәм порталда, Республика порталында авторизация узарга тиеш. Бердәм порталда, Татарстан Республикасы порталындагы «Шәхси кабинет»та авторизацияләнгәннән соң мөрәҗәгать итүче элек бирелгән гаризаларын һәм хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтү нәтиҗәләрен карау мөмкинлеген ала.

2.14. Башка таләпләр, шул исәптән:

күпфункцияле үзәкләрдә дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен исәпкә ала торган;

Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте турында белешмәләр бирү турында.

Гариза һәм документлар (документларның күчермәләре) Дәүләт комитетына «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлыфедераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) һәм 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә квалификацияле электрон имза белән имзаланган (таныкланган) электрон документлар рәвешендә җибәрелергә мөмкин

Мөрәҗәгать итүче Дәүләт комитетының туристлык индустриясен үстерү бүлегенә (алга таба – Бүлек) шәхсән, телефон һәм (яки) электрон почта, почта аша мөрәҗәгать иткәндә консультация бирелергә мөмкин.

Дәүләт хезмәте, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап, аның яшәгән урынына яки фактта яшәгән (торган) урынына бәйсез рәвештә, теләсә кайсы күпфункцияле үзәктә экстерриториаль принцип буенча урнашу урыны күрсәтелә.

Мөрәҗәгать итүчеләрне Дәүләт комитетында, КФҮ кабул итүгә язу (алга таба – кабул итүгә язу) Дәүләт комитеты, КФҮ элемтә үзәге телефоны буенча гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүчегә күпфункцияле үзәктә билгеләнгән кабул итү графигы чикләрендә теләсә нинди буш кабул итү датасына һәм вакытына язылу мөмкинлеге бирелә.

Кабул итүгә алдан язылган очракта, мөрәҗәгать итүче күрсәткән белешмәләр мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул иткәндә тапшырылган документларга туры килмәгән очракта, алдан язылу гамәлдән чыгарыла.

Кабул итүгә алдан язылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә талон-раслама чыгартып алу мөмкинлеге бирелә. Әгәр мөрәҗәгать итүче электрон почта адресын күрсәтсә, күрсәтелгән адреска шулай ук кабул итү датасын, вакытын һәм урынын күрсәтеп, алдан язылуны раслау турында мәгълүмат җибәрелә.

Кабул итүгә алдан язылган вакытта билгеләнгән кабул итү вакыты башланып, 15 минут узганнан соң да килмәгән очракта, мөрәҗәгать итүчегә алдан язылуның гамәлдән чыгарылуы турында зарури тәртиптә мәгълүмат җиткерелә.

Мөрәҗәгать итүче теләсә кайсы вакытта алдан язылудан баш тарта ала.

Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә идентификация һәм аутентификация узудан, кабул итү максатын күрсәтүдән, шулай ук кабул итү өчен алдан ук билгеләп куелырга тиешле кирәкле вакыт озынлыгын исәпләүдә кирәкле белешмәләрне тапшырудан тыш, мөрәҗәгать итүчедән башка гамәлләр башкаруны таләп итү тыела.

Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла.

Язма мөрәҗәгать буенча Дәүләт комитетының дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган хезмәткәре мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен һәм Регламент пунктында күрсәтелгән мәсьәләләрне җентекле рәвештә язмача аңлатып бирә һәм законнарда билгеләнгән срок эчендә мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрә. Җаваплар мөрәҗәгать итү телендә бирелә. Мөрәҗәгать итү телендә җавап бирү мөмкин булмаган очракта, Татарстан Республикасы дәүләт телләре кулланыла.

2.14.1. Электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүче түбәндәгеләргә хокуклы:

а) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Бердәм порталда һәм Татарстан Республикасы порталында урнаштырылган мәгълүматны алырга;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон үрнәкләре элегрәк «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон) 16 статьясының 1 өлешендәге 72 пункты нигезендә таныкланган документларны һәм мәгълүматны Бердәм порталдан, Татарстан Республикасы порталыннан файдаланып тапшырырга;

в) электрон формада тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы турында белешмәләр алырга;

г) Бердәм порталдан, Татарстан Республикасы порталыннан файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатына бәя бирергә;

д) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон белдерү формасында алырга;

е) дәүләт хезмәтләре күрсәтә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган Бердәм портал, Татарстан Республикасы порталы ярдәмендә Дәүләт комитеты, шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә.

2.14.3. Мөрәҗәгать итүчеләрне КФҮ кабул итүгә язу (алга таба – кабул итүгә язу) Бердәм портал, Татарстан Республикасы порталы аша, КФҮ элемтә үзәге телефоны буенча гамәлгә ашырыла.

3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәлү сроклары.

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү вариантлары исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда хаталарны һәм ялгышларны төзәтү өчен кирәкле дәүләт хезмәте күрсәтү вариантлары

3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча бирелгән документның дубликатын бирү өчен вариантлар исемлеге, шул исәптән мондый дубликатны бирүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документ дубликатын бирү бердәм вариантта гамәлгә ашырыла һәм бирү сроклары, мөрәҗәгать итүчеләрнең категорияләре, түләү күләме һәм тәртибе, дубликат бирү өчен кирәкле документлар исемлеге, дубликат бирү нәтиҗәсендә барлыкка килә торган документлар һәм юридик яктан әһәмиятле гамәлләр белән аерыла.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе булган документны бозган яки югалткан очракта, Дәүләт комитетына документ дубликатын бирү турында гариза белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Дубликат бирү процедурасын башлау өчен Дәүләт комитетына Дәүләт комитеты рәисе исеменә (алга таба – Рәис) дубликат бирү сәбәбен күрсәтеп, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документның дубликатын бирү турында гариза керүе нигез булып тора.

Дәүләт комитетына кергән гариза Дәүләт комитетында эш башкаруны алып бару һәм гаризаларны теркәү өчен җаваплы кадрлар һәм юридик эш бүлеге белгече (алга таба – Эшчәнлек алып баручы зат) кабул ителгән көнне теркәлә һәм 1 (бер) эш көне дәвамында Рәис урынбасарына (алга таба – Рәис урынбасары) карау өчен тапшырыла.

Рәис урынбасары 1 (бер) эш көне дәвамында гаризаны карый һәм башкару өчен Бүлек җитәкчесенә тапшыра. 2 (ике) эш көне дәвамында Бүлек хезмәткәре документның, шул ук теркәү номерын һәм датасын биреп, дубликатын рәсмиләштерә, өске почмакта «ДУБЛИКАТ» дип язылган язу кертелә һәм әзер документның дубликаты шәхсән кулына имза куеп бирелә яки почта аша заказлы хат белән гаризада күрсәтелгән адреска җибәрелә.

Процедураның нәтиҗәсе булып дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчегә бирелгән документның дубликатын бирү тора.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчегә бирелгән документның дубликатын бирүдән баш тарту өчен нигез юк.

3.2. Мөрәҗәгать итүченең гаризасын профиль буенча юллау административ процедурасын тасвирлау

Мөрәҗәгать итүченең гаризасын профиль буенча җибәрү гамәлгә ашырылмый.

3.3. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлләр эзлеклелегенә тасвирлама.

3.3.1. Социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү һәм аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә;

2) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

3) ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

4) бәяләмә проекты яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле хәбәр әзерләү;

5) мөрәҗәгать итүчегә бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезләнгән белдерү бирү;

6) техник хатаны төзәтү.

3.4. Мөрәҗәгать итүчегә консультацияләр бирү.

3.4.1. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итүе административ процедураны башкару өчен нигез булып тора.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи зат (хезмәткәр) булып түбәндәгеләр тора:

мөрәҗәгать итүче күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать иткәндә – күпфункцияле үзәк хезмәткәре;

мөрәҗәгать итүче Дәүләт комитетына мөрәҗәгать иткәндә – дәүләт хезмәте күрсәтү аның вазыйфаи бурычларына карый торган Бүлек җитәкчесе.

3.4.2. Мөрәҗәгать итүче, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында консультация сорап, күпфункцияле үзәккә шәхсән үзе һәм телефон һәм электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Күпфункцияле үзәк хезмәткәре мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырыла торган документларның составы, формасы буенча һәм башка мәсьәләләрдә дә.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турындагы мәгълүматны күпфункцияле үзәк (http://mfc16.tatarstan.ru/) сайтыннан ирекле файдалану юлы белән алырга мөмкин.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның составы, формасы буенча һәм башка мәсьәләләрдә консультацияләү.

3.4.3. Мөрәҗәгать итүче Дәүләт комитетына шәхсән, телефон һәм электрон почта буенча мөрәҗәгать итәргә, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында, шул исәптән тапшырыла торган документларның составы, формасы турында һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле башка мәсьәләләр буенча да, Бердәм порталдан, Татарстан Республикасы порталыннан, Дәүләт комитеты сайтыннан консультация алырга хокуклы.

3.4.4. Бүлек (Бүлек җитәкчесе) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында, Дәүләт комитетының урнашу урыны, белешмә телефоннары, эш вакыты турында, дәүләт хезмәте күрсәтүгә гаризаларны кабул итү графигы турында мәгълүмат бирә һәм мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентта билгеләнгән вакыт эчендә, мөрәҗәгать кергән көннән алып башкарыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның составы, формасы буенча һәм башка мәсьәләләрдә консультацияләр.

3.5. Мөрәҗәгать итүче тапшырган документлар комплектын кабул итү һәм карау.

3.5.1. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен КФҮ мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Дәүләт комитеты белән КФҮ арасындагы үзара хезмәттәшлек итү тәртибе – Дәүләт комитеты белән КФҮ арасында төзелә торган хезмәттәшлек турындагы килешү (алга таба – Килешү) белән, ә КФҮ мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү тәртибе КФҮ эш регламентында җайга салына.

Дәүләт хезмәте, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап, аның яшәгән урынына яки фактта яшәгән (торган) урынына бәйсез рәвештә, теләсә кайсы күпфункцияле үзәктә экстерриториаль принцип буенча урнашу урыны күрсәтелә. КФҮ аша дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документларны кабул итү КФҮ регламенты һәм Килешү нигезендә гамәлгә ашырыла.

Техник мөмкинлек булган очракта, кирәкле документларны электрон рәвештә тапшыру (күпфункцияле үзәкнең электрон санлы имзасы белән имзаланган документларның скан-үрнәкләре) күпфункцияле үзәкнең мәгълүмат системасы аша башкарыла. Бу очракта, кәгазьдәге документлар Килешүдә күрсәтелгән вакыт аралыгында Дәүләт комитетына җибәрелә.

Гариза һәм документлар мөрәҗәгать итүченең вәкиле тарафыннан мөрәҗәгать итүченең вәкаләтен раслаучы ышаныч кәгазе бирелгәндә тапшырырга мөмкин.

Күпфункцияле үзәк хезмәткәре мөрәҗәгать итүчедән кабул ителгән электрон формадагы (электрон эшләр пакетлары составында) документлар пакетын мөрәҗәгать итүче күпфункцияле үзәкнең структур бүлекчәсенә мөрәҗәгать иткән көннән башлап бер эш көне эчендә Дәүләт комитетына тапшыра.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: электрон багланышлар системасы аша Дәүләт комитетына җибәрелгән гариза һәм документлар пакеты (электрон эш).

3.5.1.2. Гаризаларны кабул итүче күпфункцияле үзәк хезмәткәре:

мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклый;

мөрәҗәгатьнең предметын билгели;

документлар тапшыручы затның вәкаләтләрен тикшерә;

документларның Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килү-килмәвен тикшерә;

КФҮ автоматлаштырылган мәгълүмат системасында (алга таба – КФҮ АМС) гаризаның электрон формасын тутыра;

Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документлар кәгазьдә тапшырылган очракта, тапшырылган документларны сканер аша уздыра;

Автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан гаризаны бастырып чыгара;

тикшереп чыгу һәм имзалау өчен мөрәҗәгать итүчегә бирә;

имзаланганнан соң имзаланган гаризаны Автоматлаштырылган мәгълүмат системасына сканер аша кертә;

электрон формада тапшырылган документларны яки документларның сканер аша уздырылган электрон үрнәкләрен Автоматлаштырылган мәгълүмат системасына кертә, электрон эш формалаштыра;

имзаланган гаризаны һәм кәгазь документларның оригиналларын кире кайтара;

мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итү буенча язу бирә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: җибәрүгә әзер гариза һәм документлар пакеты.

3.5.2. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтеннән электрон формада файдалану өчен Бердәм портал, Татарстан Республикасы порталы аша мөрәҗәгать итә ала, моның өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәге гамәлләрне башкара:

Бердәм порталда, Татарстан Республикасы порталында авторизацияләнә;

Бердәм порталда, Татарстан Республикасы порталында электрон гариза рәвешен ача;

шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә риза булуын раслый (электрон гариза формасында тиешле билге билгели);

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

электрон формадагы документларны яки электрон документ үрнәкләрен электрон гариза формасына беркетә (кирәк булганда);

электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамга билгели);

хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза рәвешендә тиешле тамга билгели);

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза рәвешендәге тиешле төймәгә баса);

электрон гариза 63-ФЗ номерлы Федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә (гади электрон имза белән һәм (яки) көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән) имзалана;

электрон гаризаның җибәрелүе турында белдерү ала.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: электрон багланышлар системасы аша Дәүләт комитетына җибәрелгән электрон эш.

3.5.3. Дәүләт комитетына мөрәҗәгать итүчедән турыдан-туры документар формада яки почта аша заказлы хат итеп яки Дәүләт комитеты сайтына электрон формада алынган документлар тупланмасын карау.

3.5.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документларның алынуы административ процедура үтәлешен башлау нигезе булып тора.

Шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта, мөрәҗәгать итүче (аның вәкиле) Эшчәнлек алып баручы затка гаризаны шәхсән тапшыра.

Эшчәнлек алып баручы зат:

мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклый яки мөрәҗәгать итүченең законлы вәкиле буларак катнашучы затның яисә аның тарафыннан вәкаләт бирелгән затның вәкаләтләрен тикшерә;

Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документларның булу-булмавын һәм аларның билгеләнгән таләпләргә җавап бирү-бирмәвен тикшерә. Тикшерү Бүлек җитәкчесе (Бүлек җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы зат) катнашында гамәлгә ашырыла;

документларны кабул итүдән баш тарту өчен Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән нигезләр булу-булмавын тикшерә.

Мөрәҗәгать итүче документларның күчермәләрен таныкламыйча тапшырган очракта, Эшчәнлек алып баручы зат, оригиналы булган очракта, аларны чагыштыра һәм документларның күчермәләрен үзенең имзасы белән таныклый.

Мөрәҗәгать итүче шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, документларны кабул итүдән Регламентның 2.7 пунктында каралган баш тарту нигезләре булган очракта, эшчәнлек башкаручы зат мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итүдән һәм гаризаны теркәүдән баш тарту нигезләре булуы турында хәбәр итә һәм аңа, баш тарту өчен ачыкланган нигезләр эчтәлеген аңлатып, документларны кире кайтарып бирә. Мөрәҗәгать итүченең таләбе буенча баш тарту язмача рәвештә рәсмиләштерелә.

Мөрәҗәгать итүче гаризаны һәм документларны почта аша (электрон почтадан) җибәргән очракта, Эшчәнлек алып баручы зат, баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген язмача аңлатып, документларны аңа почта аша (электрон почтадан) җибәрә.

Документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре булмаган очракта, Эшчәнлек алып баручы зат:

гаризаны кабул итә һәм терки;

документларны кабул итү датасы һәм вакыты, кергәндә беркетелгән номеры турында тамгалап, белдерү күчермәсен мөрәҗәгать итүчегә тапшыра яки почта буенча яки электрон почта (аның ихтыярына карап) аша җибәрә;

гаризаны электрон формада «Электрон Хөкүмәт» Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының электрон документлар әйләнеше буенча бердәм ведомствоара системасы (алга таба – электрон документ әйләнеше) аша Рәискә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза алынган көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм карау өчен Рәискә җибәрелгән гариза яисә, кире кайтару сәбәпләрен аңлатып, мөрәҗәгать итүчегә кире кайтарылган документлар.

3.5.3.2. Рәис мөрәҗәгатьне карый һәм карау өчен Рәис урынбасарына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Рәис урынбасарына карау өчен җибәрелгән гариза.

3.5.4. Рәис урынбасары гаризаны карый һәм үтәү өчен Бүлек җитәкчесенә (Бүлек җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы затка) җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза теркәлгән көннән башлап бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек җитәкчесенә (Бүлек җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы затка) үтәү өчен җибәрелгән гариза.

3.6. Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү.

3.6.1. Бүлек җитәкчесе (Бүлек җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы зат) мөрәҗәгать итүче Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән белешмәләрне (документларны) тапшырмаган очракта, Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документлар исемлеге нигезендә белешмәләр алу өчен дәүләт хезмәтләре күрсәтүдә катнашучы органнарга (оешмаларга) ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы каналлары буенча җибәрелгән ведомствоара рәсми мөрәҗәгать.

3.6.2. Белешмәләр белән тәэмин итүче белгечләр ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша алынган рәсми мөрәҗәгать нигезендә сорала торган документларны (белешмәләрне) законнарда билгеләнгән чорда бирә.

Процедураларның нәтиҗәсе: Дәүләт комитетына рәсми мөрәҗәгатькә җибәрелгән җаваплар яисә сорала торган документларның (белешмәләрнең) булмавы турында белдерү.

3.6.3. Дәүләт комитетына бәяләмә бирү турында гариза алынганда һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 22 августындагы 681 номерлы карары белән расланган Нигезләмә нигезендә иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтү сыйфатын бәяләү берничә башкарма хакимият органы, шул исәптән Дәүләт комитеты тарафыннан да гамәлгә ашырылса, бәяләмә Дәүләт комитеты тарафыннан бирелә. Зарурлык булганда Дәүләт комитеты мәнфәгатьле башка органнардан, шулай ук башка дәүләт хакимияте органнарыннан ведомствоара мәгълүмат хезмәттәшлеге тәртибендә белешмәләр сората.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура Бүлек җитәкчесенә (Бүлек җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы затка) гариза алынганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм җибәрү, дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм башка оешмалардан аларда булган белешмәләрнең, ведомствоара рәсми мөрәҗәгатькә җавап килүе.

3.7. Бәяләмә бирү турында карар әзерләү һәм кабул итү яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле хәбәр әзерләү.

3.7.1. Бүлек җитәкчесе (Бүлек җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы зат) рәсми мөрҗәгатьләргә алынган һәм мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документлар нигезендә Регламентның 2.8 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләре булу-булмавын тикшерә.

Регламентның 2.8 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтүдән (бәяләмә бирүдән) баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, теркәлеп бара торган зат проектын, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 26 гыйнварындагы 89 номерлы карарына 2 номерлы кушымта нигезендә бәяләмә әзерли һәм килештерү өчен Рәис урынбасарына җибәрә.

Регламентның 2.8 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтүдән (бәяләмә бирүдән) баш тарту өчен нигезләр булган очракта, Регламентның 2 нче кушымтасы нигезендә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белдерү кәгазе белән теркәләп бара торган хат проектын әзерли һәм килештерү өчен Рәис урынбасарына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар рәсми мөрәҗәгатьләргә җаваплар алынганнан соң дүрт эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: килештерү өчен Рәис урынбасарына җибәрелгән теркәлеп бара торган хат, бәяләмә проектлары яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белдерү проекты.

3.7.2. Рәис урынбасары теркәлеп бара торган хат, бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белдерү проектларын килештерә һәм аларны Рәискә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура әлеге проектлар килештерү өчен алынган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: килештерелгән һәм карау өчен Рәискә җибәрелгән теркәлеп бара торган хат, бәяләмә проектлары яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белдерү проекты.

3.7.3. Рәис теркәлеп бара торган хатны белән бергә бәяләмәне яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белдерүне имзалый һәм аларны Бүлеккә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Рәис тарафыннан имзаланган, Бүлеккә җибәрелгән теркәлеп бара торган хат белән бергә бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белдерү.

3.7.4. Бүлек җитәкчесе (Бүлек җитәкчесе вазыйфаларын башкара торган зат), рәсми мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән элемтә ысулыннан файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итә, бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерү белән бергә теркәлә торган хатны теркәү өчен Эшчәнлек алып баручы затка тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура Рәис теркәлеп бара торган хат белән бергә бәяләмәне яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белдерүне имзалаган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: теркәү өчен Эшчәнлек алып баручы затка тапшырылган теркәлеп бара торган хат белән бергә бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белдерү.

3.8. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен юллау.

3.8.1. Эшчәнлек алып баручы зат:

теркәлеп бара торган хат белән бергә бәяләмәне яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белдерүне терки;

имзаланган бәяләмәне яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белдерүне рәсми мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән ысул белән мөрәҗәгать итүчегә җибәрә (бирә).

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар түбәндәгечә башкарыла:

бәяләмәне (бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белдерүне) почта аша җибәргән очракта – Рәис бәяләмәне (бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белдерүне) имзалаган көннән башлап бер эш көне эчендә;

гаризада бәяләмәне (бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезләнгән хәбәрләмәне) шәхсән алу турында күрсәтелгәндә - мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне.

Процедураларның нәтиҗәсе: бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерү белән бергә теркәлгән, мөрәҗәгать итүчегә җибәрелгән (тапшырылган) теркәлә торган хат.

3.9. Татарстан Республикасы Хөкүмәте рәсми порталының Интернет-кабул итү системасы аша алынган гаризаны карау.

Интернет-кабул итү системасы аша алынган гариза Регламентның 3.5-3.8 пунктларында каралган тәртиптә теркәлә һәм карала.

3.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү

3.10.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе аны алу буенча сайланган ысул белән мөрәҗәгать итүчегә бирелә (җибәрелә):

язмача формада мөрәҗәгать итүчегә шәхсән Дәүләт комитетында яки мөрәҗәгать итүченең яшәү яки тору урыны буенча почта юлламасы белән; электрон почта адресы буенча электрон документ формасында, Татарстан Республикасы порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына электрон документ формасында.

3.10.1.1. Мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүченең вәкиле) Дәүләт комитетына шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта, Бүлек җитәкчесе мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 26 гыйнварындагы 89 номерлы карары белән расланган Кагыйдәләрнең 2 нче кушымтасы нигезендәге форма буенча дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен яисә кәгазь чыганакта электрон документ нөсхәсе формасында Регламентның 2 нче кушымтасы нигезендәге форма буенча бәяләмә бирүдән баш тарту турында мотивацияле белдерү бирә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар дәүләт хезмәте күрсәтүне (күрсәтүдән баш тартуны) раслаучы документ имзаланган көнне, Бүлек җитәкчесе тарафыннан башкарыла.

3.10.1.2. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе артыннан КФҮ мөрәҗәгать иткән очракта, КФҮ хезмәткәре мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 26 гыйнварындагы 89 номерлы карары белән расланган Кагыйдәләрнең 2 нче кушымтасы нигезендәге форма буенча дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен яисә кәгазь чыганакта электрон документ нөсхәсе формасында Регламентның 2 нче кушымтасы нигезендәге форма буенча бәяләмә бирүдән баш тарту турында мотивацияле белдерү бирә. Мөрәҗәгать итүче таләбенә карап, кәгазьдәге электрон документ нөсхәсе белән аңа, алынмалы-куелмалы саклагыч җайланмага яздыру юлы белән, электрон документ нөсхәсе дә бирелә ала.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар чират тәртибендә, мөрәҗәгать итүче килгән көнне күпфункцияле үзәкнең эш регламентында билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.

техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны электрон документ әйләнеше системасы аша электрон формада Рәискә җибәрү.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура техник хатаны төзәтү турында гариза алынган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм Рәискә җибәрелгән техник хатаны төзәтү турында гариза.

3.11.2. Рәис техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны карый һәм карау өчен Рәис урынбасарына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура техник хатаны төзәтү турында гариза теркәлгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Рәис урынбасарына карау өчен җибәрелгән техник хатаны төзәтү турында гариза.

3.11.3. Рәис урынбасары техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны карый һәм карау өчен Бүлек җитәкчесенә (Бүлек җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы затка) җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура техник хатаны төзәтү турында гариза теркәлгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек җитәкчесенә (Бүлек җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы затка) карау өчен җибәрелгән техник хатаны төзәтү турындагы гариза.

3.11.4. Бүлек җитәкчесе (Бүлек җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы зат):

теркәлә торган хат, үзгәртеп рәсмиләштерелгән бәяләмә проекты яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерү проекты әзерли;

теркәлә торган хатны, үзгәртеп рәсмиләштерелгән бәяләмә проектын яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерү проектын килештерү өчен Рәис урынасарына юллый.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар Бүлек җитәкчесенә (Бүлек җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы затка) техник хатаны төзәтү турында гариза җибәрелгәннән соң ике эш коне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Рәис урынбасарына килештерү өчен җибәрелгән теркәлеп бара торган хат, үзгәртеп рәсмиләштерелгән бәяләмә проекты яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белдерү проекты.

3.11.5. Рәис урынбасары теркәлә торган хатны, үзгәртеп рәсмиләштерелгән бәяләмә проектын яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерү проектын килештерә һәм Дәүләт комитеты рәисенә юллый.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура теркәлеп бара торган хат, үзгәртеп рәсмиләштерелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белдерү Бүлек җитәкчесеннән (Бүлек җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы заттан) алынган көннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Рәис урынбасары тарафыннан килештерелгән һәм карау өчен Рәискә җибәрелгән теркәлеп бара торган хат, үзгәртеп рәсмиләштерелгән бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белдерү проектлары.

3.11.6. Рәис теркәлеп бара торган хат белән бергә үзгәртеп рәсмиләштерелгән бәяләмәне яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белдерүне имзалый һәм аларны Бүлеккә җибәрә.

3.10.1.3. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буенча Татарстан Республикасы порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документның Рәиснең көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон рәвеше мөрәҗәгать итүчегә автомат рәвештә шәхси кабинетка җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар дәүләт хезмәте күрсәтүне (күрсәтүдән баш тартуны) раслаучы документ имзаланган көнне, Эшчәнлек алып баручы зат тарафыннан башкарыла.

3.10.2. Мөрәҗәгать итүче, аның вәкиле дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу өчен Дәүләт комитетына шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта, документларны бирүгә җаваплы булган Бүлек җитәкчесе:

мөрәҗәгать итүченең шәхесен билгели, шул исәптән шәхесне раслаучы документны тикшерә;

вәкилнең вәкаләтләрен тикшерә (боерык, ышаныч кәгазе һ.б.);

мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен бирә һәм исәпкә алу кенәгәсендә документ бирү турында язу терки;

теркәү хатын бирә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче килгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 26 гыйнварындагы 89 номерлы карарына 2 нче кушымта нигезендә форма буенча дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен яисә Регламентның 2 нче кушымтасы нигезендә форма буенча бәяләмә бирүдән баш тарту турында мотивацияле белдерү җибәрү (бирү)

3.11. Техник хатаны төзәтү.

Бәяләмәне яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерүне үзгәртеп рәсмиләштерү элегрәк бирелгән бәяләмәдә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерүдә җибәрелгән техник хаталарны (язу хатасын, басма хаталарны, грамматик яки арифметик хаталарны) бетерүгә бәйле рәвештә гамәлгә ашырыла.

Бәяләмәне яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белдерүне үзгәртеп рәсмиләштерү Регламентның 3 нче кушымтасына туры китерелгән форма буенча төзелгән техник хатаны төзәтү турында теркәлгән гариза (алга таба – техник хатаны төзәтү турында гариза) нигезендә гамәлгә ашырыла, ул Регламентның 3.5.3 пунктында күрсәтелгән ысулларның берсе буенча тапшырыла. Техник хатаны төзәтү турындагы гаризага дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак мөрәҗәгать итүчегә бирелгән, техник хатасы булган бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилле белдерү, шулай ук, документлар мөрәҗәгать итүче вәкиле тарафыннан тапшырылган очракта, мөрәҗәгать итүче вәкиленең мөрәҗәгать итүче исеменнән эш итү өчен кирәкле вәкаләтләрен таныклый торган ышаныч кәгазе теркәлә.

Техник хаталарны электрон формада һәм КФҮ аша төзәтеп булмый.

3.11.1. Эшчәнлек алып баручы зат:

электрон документ әйләнеше системасында техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кабул итү һәм теркәү;

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Рәис тарафыннан имзаланган, Бүлеккә җибәрелгән теркәлеп бара торган хат белән бергә үзгәртеп рәсмиләштерелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белдерү.

3.11.7. Бүлек җитәкчесе (Бүлек җитәкчесе вазыйфаларын башкара торган зат), рәсми мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән элемтә ысулыннан файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итә, бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле, үзгәртеп рәсмиләштерелгән белдерү белән бергә теркәлә торган хатны теркәү өчен Эшчәнлек алып баручы затка тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: теркәү өчен Эшчәнлек алып баручы затка тапшырылган теркәлеп бара торган хат белән бергә үзгәртеп рәсмиләштерелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белдерү.

3.11.8. Эшчәнлек алып баручы зат:

теркәлеп бара торган хат белән бергә үзгәртеп рәсмиләштерелгән бәяләмәне яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белдерүне терки;

техник хатаны төзәтү турында гаризада күрсәтелгән ысул белән (шәхсән, почта аша) имзаланган, үзгәртеп рәсмиләштерелгән бәяләмәне (бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белдерүне) тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

үзгәртеп рәсмиләштерелгән бәяләмәне (бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белдерүне) почта аша җибәргән очракта – Рәис теркәлеп бара торган хат белән бергә үзгәртеп рәсмиләштерелгән бәяләмәне яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белдерүне имзалаган көннән соң бер эш көне эчендә;

гаризада үзгәртеп рәсмиләштерелгән бәяләмәне (бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезләнгән хәбәрләмәне) шәхсән алу турында күрсәтелгәндә - мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә җибәрелгән (бирелгән) теркәлеп бара торган хат белән бергә үзгәртеп рәсмиләштерелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белдерү.

## 4. Административ регламент үтәлешен контрольдә тоту формалары

4.1. Дәүләт комитеты вазыйфаи затларының әлеге Регламенттагы һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган башка норматив хокукый актлардагы нигезләмәләрне үтәвен һәм башкаруын, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул ителүне тикшереп тору тиешле административ процедураны үтәү өчен җаваплы зат һәм дәүләт хезмәте күрсәтү буенча эшне оештыру өчен җаваплы булган Рәис урынбасары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.2. Агымдагы контрольлек Дәүләт комитеты вазыйфаи затларының Регламентта һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган башка норматив хокукый актлардагы нигезләмәләрне үтәвенә һәм башкаруына тикшерүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Агымдагы тикшереп тору даими нигездә гамәлгә ашырыла.

4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору тикшерүләр үткәрү, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) һәм карарларына кагылышлы шикаятьләрне үз эченә алган мөрәҗәгатьләрне карап тикшерү, алар буенча карарлар кабул итү һәм җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольлектә тоту рәвешләре булып түбәндәгеләргә карата тикшерүләр үткәрү тора:

эшнең алып барылуына;

документларны карап тикшерү нәтиҗәләренең законнардагы (Регламенттагы) таләпләргә туры килү-килмәвенә;

документларны кабул итүнең чорлары һәм тәртибе саклануга;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә нәтиҗәләр тапшыру чорлары һәм тәртибе саклануга.

Тикшерүләрне үткәрү ешлыгы планлы характерга (эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш характерга (мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча) ия.

4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын планнан тыш тикшерү турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

Регламенттагы һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган норматив хокукый актлардагы таләпләрне бозуның элек ачыкланган очракларын юкка чыгаруны тикшерүгә бәйле рәвештә;

юридик затлар Дәүләт комитетының дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган вазыйфаи затлары гамәлләренең (гамәл кылмавы) үзләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуга бәйле шикаятьләр белән мөрәҗәгать иткәндә.

4.5. Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә Мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган, гаепле дип танылган вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.6. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүне контрольлектә тоту дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Дәүләт комитеты эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм төгәл мәгълүматны алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү барышында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәрге тәртиптә карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе.

5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы Дәүләт комитеты, Дәүләт комитетының вазыйфаи заты яисә дәүләт граждан хезмәткәре,

КФҮ, КФҮ хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәрге тәртиптә Дәүләт комитетына шикаять белдерергә хокуклы. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә Рәис тарафыннан кабул ителгән карарларга, гамәлләргә (гамәл кылмауга) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына белдерелә.

Күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр әлеге күпфункцияле үзәк җитәкчесенә тапшырыла.

КФҮ карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр КФҮ оештыручы затка (алга таба – КФҮ гамәлгә куючы затка) бирелә.

5.2. Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгатьне теркәү срогы бозылганда;

дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты бозылганда;

Мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәте күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы күздә тотылмаган документларны яки мәгълүматлар тапшыру яисә гамәлләр башкару таләп ителгәндә;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм бүтән норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

Дәүләт комитетынын, аның вазыйфаи затының, КФҮ, КФҮ хезмәткәренең дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда үзләре тарафыннан җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү чоры яисә тәртибе бозылганда;

дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда Мөрәҗәгать итүчедән, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп ителгәндә.

5.3. Шикаять кәгазьдә язмача яки электрон рәвештә тапшырыла.

Шикаять почтадан, КФҮ, «Интернет» челтәреннән файдаланып, Дәүләт комитетының (http://tourism.tatarstan.ru/) рәсми сайтыннан, Татарстан Республикасы порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru/), Бердәм порталдан (http://www.gosuslugi.ru) җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул итеп алынырга мөмкин.

КФҮ, КФҮ хезмәткәре, Дәүләт комитеты, Дәүләт комитетының вазыйфаи заты, Рәис карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять почтадан, «Интернет» челтәреннән файдаланып, күпфункцияле үзәктән, Дәүләт комитетының рәсми сайтыннан (http://tourism.tatarstan.ru/), Татарстан Республикасы порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru/), Бердәм порталдан (http://www.gosuslugi.ru/) җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә кабул итеп алынырга мөмкин.

5.4. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затның яисә граждан хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, аның җитәкчесенең һәм (яки) хезмәткәренең исеме;

мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турындагы белешмәләр, мөрәҗәгать итүче – юридик затның атамасы, урнашкан урыны турындагы белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтә торган органдагы вазыйфаи затның яисә дәүләт хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең шикаять белдерелгән карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезли торган дәлилләр.

5.5. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.6. Шикаять алынган көненнән соңгы эш көне узганчы теркәлергә тиеш.

Шикаятьне карап тикшерү чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы 15 эш көне эчендә. Дәүләт комитетының, Дәүләт комитеты вазыйфаи затының мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгән очракта яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылганда, – теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән язу һәм басма хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив

хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә;

шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

5.8. Регламентның 5.7 пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соңгы көннән соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүчегә язмача формада яки, аның ихтыярына карап, электрон формада шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

5.9. Шикаятьне Регламентның 5.8 пунктында күрсәтелгән җавапта канәгатьләндерелергә тиешле дип тану очрагында, дәүләт хезмәте күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатларында Дәүләт комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәте күрсәтү максатларында мөрәҗәгать итүчегә киләчәк гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.10. Шикаять канәгатьләндерелергә тиешле түгел дип танылган очракта, әлеге Регламентның 5.8 пунктында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.11. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

5.12. Дәүләт комитеты, шулай ук аның вазыйфаи затлары, яки дәүләт хезмәткәрләре, КФҮ, КФҮ хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләр 210-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә җайга салына.

_________________________________________________________________________________.

(иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүдә турыдан-туры катнашучы затларның (шул исәптән оешмаларның хезмәткәрләренең һәм граждани-хокукый холыклы килешүләр буенча җәлеп ителгән хезмәткәрләрнең) кирәкле квалификациясе (шул исәптән һөнәри юридик белеменең, тиешле өлкәдәге эш тәҗрибәсенең) булуы, мондый затларның тиешле санда булуын раслау)

_________________________________________________________________________________

_________________________________________________________________________________

_________________________________________________________________________________.

(иҗтимагый файдалы хезмәтләрдән файдаланучы затларның аларны күрсәтү сыйфатыннан канәгать калуын раслау (бәяләмә бирелә торган елдан алдагы 2 ел эчендә оешма тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрне күрсәтүгә бәйле оешма гамәлләренә (гамәл кылмавына) һәм (яки) карарларына суд, дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль күзәтчелек органнары, компетенцияләренә туры китереп, башка органнар тарафыннан нигезле дип танылган шикаятьләрнең булмавы)

_________________________________________________________________________________.

(коммерциясез оешма турында мәгълүматның ачыклыгын һәм һәркем файдалана алырлык булуын раслау)

_________________________________________________________________________________.

(оешманың бәяләмә бирелгән елдан алдагы 2 ел дәвамында «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр күрсәтү сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән контрактларны үтәү кысаларында хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча намуссыз тәэминатчылар реестрында булмавын раслау)

Раслый торган документлар теркәлә:

_________________________________________________________________________________.

1. _______________________________________________________________________________

2. _______________________________________________________________________________

3. _______________________________________________________________________________

һ.б.

_________________________________________________________________________________.

(вазыйфа) (имза) (Ф.И.А.)

«__» ________ 20__ ел.

Мөһер урыны (булган очракта)

Социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

(формасы)

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитеты рәисенә

______________________________
(фамилия, инициаллар)

______________________________
______________________________
(оешманың исеме, адресы
(почта һәм (яки) электрон),
телефон номеры (булган очракта)

Гариза

Социаль юнәлешле коммерциясез оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр сыйфатының туры килүе турында бәяләмә бирүегез турында сорыйм
______________________________________________________________.
(социаль юнәлешле коммерциясез оешма атамасы)

иҗтимагый файдалы хезмәтләр
______________________________________________________________.
(иҗтимагый файдалы хезмәт атамасы)

аларны күрсәтү өлкәсендә билгеләнгән критерийларга.

Оешманың чит ил агенты функцияләрен башкаручы коммерциясез оешма булып тормавын һәм бер ел һәм аннан күбрәк чорда Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Иҗтимагый файдалы хезмәтләр исемлеген һәм аларны күрсәтү сыйфатын бәяләү критерияләрен раслау турында» 2016 елның 27 октябрендәге 1096 номерлы карарында расланган иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын бәяләү критерияләренә туры килүче атап үтелгән иҗтимагый файдалы хезмәтләрне күрсәтүе турында раслыйбыз.

______________________________________________________________
______________________________________________________________
______________________________________________________________.
(иҗтимагый файдалы хезмәтнең Россия Федерациясе норматив хокукый актларында аның эчтәлегенә (күләменә, срокларына, күрсәтү сыйфатына) карата билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслау);

Социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тарафыннан күрсәтелүче иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең билгеләнгән критерияләргә туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
2 нче кушымта

(киңәш ителә торган рәвеше)

## Социаль юнәлешле коммерциясез оешма тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерү

Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәяләү нәтиҗәләре буенча социаль юнәлешле коммерциясез оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр сыйфатының туры килүе турында бәяләмә бирүдән баш тарта:

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

(социаль юнәлешле коммерциясез оешманың тулы атамасы һәм төп дәүләт теркәвенә алу номеры)

түбәндәге иҗтимагый файдалы хезмәтләр:

______________________________________________________________________;

______________________________________________________________________;

______________________________________________________________________.

(иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең атамасы)

Күрсәтелгән иҗтимагый файдалы хезмәтләр иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәяләүнең билгеләнгән критерийларына түбәндәге нигезләр буенча туры килми:

______________________________________________________________________;

______________________________________________________________________;

______________________________________________________________________.

(критерийларга туры килмәү нигезләре күрсәтелә)

Татарстан Республикасы
Туристлык буенча дәүләт комитеты рәисе ______________ ________________
имза ФИА

«____»__________20___

М.У.

Социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тарафыннан күрсәтелүче иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең билгеләнгән критерияләргә туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

(киңәш ителә торган рәвеше)

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитеты рәисенә

________________________________________________

кемнән ______________________________________

оешма исеме, адресы

(почта һәм (яки) электрон),

телефон номеры (булган очракта)

Техник хатаны төзәтү турында гариза

Социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белдерү бирелгәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм.

________________________________________________ болай дип күрсәтелгән:

(бирелгән документ)

________________________________________________________________________.

Дөрес мәгълүматлар: ______________________________________________

________________________________________________________________________.

Техник хатаны төзәтүегез һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документка тиешле үзгәрешләр кертүегез турында үтенәм.

Түбәндәге документларны терким:

1.

2.

Документның әзер булуы турында миңа түбәндәгечә хәбәр итүегез турында үтенәм

________________________________________________________________________.

(хәбәр итү ысулы)

| _______________ | ______________________________ | _______________ |
|---|---|---|
| (дата) | (мөрәҗәгать итүче/вәкил имзасы) | (Ф.И.А.) |

Мөһер урыны (булган очракта)

Социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тарафыннан күрсәтелүче иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең билгеләнгән критерияләргә туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (белешмә) кушымта

**Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен җаваплы булган һәм аның үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның реквизитлары**

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитеты

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Рәис | (843) 222-90-20 | tourism.rt@tatar.ru |
| Рәис урынбасары | (843) 222-90-22 | Gulnara.Safina1@tatar.ru |
| Туристлык индустриясен үстерү бүлеге җитәкчесе | (843) 222-90-40 | Anastasiya.Kaymanova@tatar.ru |
| Туристлык индустриясен үстерү бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе | (843) 222-90-39 | Rusalina.Gaynatulina@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты

| Адрес | Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|---|
| 420014, Казан шәһәре, Ирек мәйданы, 1 | Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсе җитәкчесе | +7 (843) 264-77-84 | Guzel.Shakirova@tatar.ru |